207
79

Ч. Айтматов атындагы тил жана адабият институту
Кол жазмалар фондусу
Инв. № 297
Кыргыз Республикасынын Улуттук илимдер академиясы
Гуманитардык жана экономикалык илимдер бөлүмү

209-79

"Хусин ал-ибада" Казанское издание 1903 г. На тюркском языке,
...о не указан.

سؤال وجوابلی

# حسن العباده

بلدهٔ قزان خدام علمندين عالم جان بن محمد جان
البارودی دست ترتيبنده اولان معارف اسلاميه دين
جزء رابعدر

Дозволено цензурою С.-Петербургъ 30 Сентября 1903 года.

КАЗАНЬ.
Типографія Б. Л. Домбровскаго.
1903.

بسم الله الرحمن الرحيم

الحمد لله رب العالمين وصلى الله على سيدنا محمد وعلى آله وصحبه اجمعين ·

## كتاب الصلوة

| سوءال | جواب |
| --- | --- |
| بنده گه هر کون نچه نماز فرض قایو نمازلار | بش نماز فرضدر * ایکی رکعت ایرته نمازی، دورت رکعت اویلی نمازی، دورت رکعت ایکندی نمازی، اوچ رکعت اخشام نمازی، دورت رکعت یستو نمازی * |
| هر کون نی قدر نماز سنت آنلر قایولار | اون ایکی رکعت نماز سنت * ایرته نمازندین اول ایکی رکعت اویلی دین اول دورت رکعت اویلی دین صونك ایکی رکعت اخشامدین صونك ایکی رکعت یستودین صونك ایکی رکعت |
| هر کون قایو نماز واجب نمازنی نی روشلی قیلمق تیوش | اوچ رکعت وتر نمازی واجبدر * فرض واجب سنت ومستحبلری ایله قیلمق ومکروهلرندین ساقلانمق لازمدر |

نمازننك فرضی قالسه
نماز نچوك اولوز

نمازده فرض قالسه نماز بوزولور
قایته روب اوقومق فرض اولور *

واجبی قالسه یا که مکروه
اش قیلونسه نچوك

نمازده واجب قالسه یا که اول نمازده بر
مکروه اش قیلونسه نماز بوزولماس
ولکن کمچیلك کلور یانکیدین یخشیلاب
اوقومق واجب اولور *

نمازنی یخشی اوقومق
ایچون نرسه لرنی بلمك
کرك

نمازننك فرضلرینی واجبلرینی
سنتلرینی مستحبلرینی مکروهلرینی
آیوره ایوره بیلمك کرك

## ( فصل الفرائض )

نمازده نی قدر فرض وار
نرسه لر

اون بش قدر فرض واردر
( ۱ ) وقت کرمکی ( ۲ ) طهارت ( ۳ )
بارچه تننك نجاستدین پاکلکی
( ۴ ) پاك اورن ( ۵ ) کیوم پاکلکی
( ۶ ) قبله غه یونالمك ( ۷ ) نیت ( ۸ )
تکبیر تحریمه ( ۹ ) قیام ( ۱۰ ) قراءت
( ۱۱ ) رکوع ( ۱۲ ) سجده ( ۱۳ ) قعدهٔ
اخیره ( ۱۴ ) ترتیب ( ۱۵ ) اختیاری
برله نمازدین چیغو *

بوفرضلرننك نچه سی
شرط نچه سی رکن
شرطنی دیکان سوز

اولگی سکزی شرطدر صونکغی یدیسی
رکن نمازننك ایچنده قیلنه در *
نمازدین اوّل اوق حاضرلمکی فرض
دیکان سوز

رکن نی نرسه

نماز ایچنده قیلمقی فرض بولغان نرسه

شرطلرننک برچیسی وقت نمازنی وقت گرکاچه اوقولسه نچوک اولور

هر فرض نمازنی وقتنده قیلمق فرضدر وقتندین الوک اوقولسه نماز درست اولماس *

وقتندین کیچوکتورلسه نچوک اولور

فرض مویندین توشار ولکن کیچوکتوروی ایچون کناهلی بولور *

ایرته نمازیننک وقتی نی وقت

راست تانک آتودین قیاش چیغوغه قدر *

نمازدین بوشانغانچی قیاش چیقسه نچوک اولور

نمازی بوزولور ایرته نمازینی قیاش چیقغانچی تمام ایتمک فرضدر *

تانک بولغاچ قیاش توغانچی باشقه نماز درست بولورمی

ایکی رکعت سنتدین باشقه نفل نمازی مکروه اولور قضا نمازی درست بولور *

اولی نمازیننک وقتی نی وقت

توش آوشقاندین باشلاب هر نرسه ننک کولاگاسی توش کولاگاسندین باشقه شول نرسه ننک اوزی اوخشاشی ایکی اولغانچی وبر روایتده بر اولغانچی *

توش وقتنده نماز درست اولورمی

فرض نماز درست اولماز نفل مکروه اولور *

ایکندی وقتی نی وقت

اولی ننک اخیر وقتندین قیاش باتقانچه در ولکن قیاشننک آق وقتنده نوری قایتقانچه اوقومق واجبدر *

ایکندی اوقوغاچ باشقه نماز درست اولورمی

قیاش باتوب اخشام اوقوغانچی نفل نمازی مکروهدر ولکی قضا نمازی درست

قیاش